## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы

## КАРАРЫ

№ 206 10.10.2019 ел.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 7 нче декабрендәге 165 нчы номерлы «Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең 2019 нчы елга һәм 2020, 2021 нче елларның планлы чорына бюджеты турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль район Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 7 нче декабрендә кабул ителгән 165 нчы номерлы "Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең 2019 нчы елга һәм 2020, 2021 нче елларның планлы чорына бюджеты турында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктында:

а) 1 өлештә "4130,2" санын "4876,0" санына алмаштырырга;

б) 2 өлештә "4216,2" санын "5021,7" санына алмаштырырга;

в) 3 өлештә " 86,0" санын "145,7" санына алмаштырырга.

1.2. 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "2019 елга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары" ның 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә редакцияне бәян итәргә;

1.3. 1 нче таблицага "2019 елга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетының фаразланган керемнәр күләме"нә 2 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакцияне бәян итәргә;

1.4. «2019 елга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 5 нче кушымтасының 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә редакцияне бәян итәргә;

1.5. «Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2019 елга бюджет чыгымнары

классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча бүлү» 6 нчы кушымтасының 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә редакциягә бәян итәргә;

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Бу карарны контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет Рәисе,**
**Авыл җирлеге башлыгы** **Л.Г.Варганова**